КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 19 август г.Казань № 711

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 22 июнь, 508 нче карары белән расланган Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 22 июнь, 508 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 12 август, 676 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидия ТЧны яңадан җиһазландырганда яңадан җиһазландыру пункты белән бирелгән ташлама күләмендә бирелә, әмма ТЧны яңадан җиһазландыруның гомуми бәясенең өчтән береннән (2020 елда – яңадан җиһазландырылган ТЧ хуҗасы булып физик зат яисә юридик зат – кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты торса (шул исәптән лизинг килешүе нигезендә) икедән береннән) һәм әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә бер ТЧ өчен субсидиянең иң чик күләменнән дә артмаска тиеш.»;

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Вәкаләтле орган, дәүләт заказчысыннан кабул итү-тапшыру акты буенча гариза алганнан соң киләсе көннән исәпләнгән бер эш көне эчендә кабул итү-тапшыру акты буенча гаризаны вәкаләтле оешмага тапшыра.»;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Вәкаләтле оешма вәкаләтле органнан гариза алганнан соң киләсе көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнгән 12 көн эчендә аны әлеге Тәртипнең 9 һәм 10 пунктларында каралган таләпләргә һәм шартларга туры килү-килмәү предметына тикшерә. Гаризаны тикшерү тәмамланганнан соң икенче эш көнендә вәкаләтле оешма тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүматны һәм кабул итү-тапшыру акты буенча гаризаны Вәкаләтле органга тапшыра.»;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Вәкаләтле оешма тарафыннан тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат һәм субсидия алу өчен гариза бирү, шулай ук дәүләт заказчысы тарафыннан ТЧны яңадан җиһазландыру буенча башкарылган эшләрне тикшерү нәтиҗәләрен бирү нәтиҗәләре буенча вәкаләтле орган, вәкаләтле оешма тарафыннан тиешле документлар бирелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә ТЧны яңадан җиһазландыруны башкаруны һәм яңадан җиһазландыру пункты тарафыннан ТЧ хуҗасына фактта бирелгән ташлама һәм аның күләмен тикшерүне гаризада һәм ТЧ хуҗасы тарафыннан газ баллоны җиһазларын сатып алуны һәм яңадан җиһазландыру буенча эшләр өчен түләүне раслаучы документларда булган эшнең

хакы һәм ТЧны яңадан җиһазландыру эшләрен башкаруга бирелгән ташламаның күләме турында мәгълүматларны чагыштыру юлы белән гамәлгә ашыра.

Вәкаләтле орган әлеге тикшерүне үткәргәннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча Субсидия бирү яисә Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.»;

21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Вәкаләтле орган тарафыннан Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, гариза һәм кабул ителгән карар вәкаләтле орган тарафыннан карар чыкканнан соң өч эш көне эчендә кабул итү-тапшыру акты буенча дәүләт заказчысына тапшырыла. Шул ук вакытта гариза бирүче үзе тапшырган документларны дәүләт заказчысыннан соратып алырга, шулай ук яңадан гариза тапшырырга хокуклы.»;

27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27. Әлеге Тәртипнең 26 пунктында Субсидия алучы тарафыннан Субсидия акчаларын кире кайтару өчен билгеләнгән вакытны бозганда вәкаләтле орган, әлеге Тәртипнең 26 пунктында күрсәтелгән вакыт тәмамланганнан соң, календарь көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияне кире кайтару буенча чаралар күрә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин